СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.08.2020 г. Заинск № 192

**«Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 104 номерлы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата бүләкләү һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен арттыру турында" 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. "Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында" 2018 елның 13 апрелендәге 104

номерлы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карар белән расланган Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.2 пунктында «11163 сум» сүзләрен “11498 сум» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Әлеге карар белән расланган "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында" нигезләмәгә 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Акчалата бүләкләү күләмнәре ».

| Вазыйфаның исеме | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 5 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 29 005 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 26 102 |
| Депутатлар | 13 899 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 11 812 |

2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре башлыгы урынбасары Е.В. Недошивинага йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**